**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 9 сентябрендәге 2817 номерлы карары**

**«Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районының Чирмешән урамында Нокса елгасы аша күпер төзү» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын раслау турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы «Территорияне планлаштыру документларын, җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләү, килештерү, раслау, аларның гамәлдә булу вакытларын озайту, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәтләр, файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү үзенчәлекләре турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы «2022, 2023, 2024 һәм 2025 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм, җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, әлеге проектларга үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында»гы карарына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 29 августындагы 3679 номерлы «“Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районының Чирмешән урамында Нокса елгасы аша күпер төзү” линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләү турында»гы карарына таянып, «Беренчел документларны әзерләү үзәге» муниципаль унитар предприятиесе гаризасы нигезендә **карар бирәм**:

1. «Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районының Чирмешән урамында Нокса елгасы аша күпер төзү» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, линия объектын план буенча урнаштыру

зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләре (1 нче этап) чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләре (2 нче этап) чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, махсус бүленгән судан файдалану чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар** **А.Р.Нигъмәтҗанов**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 9 сентябрендәге
2817 номерлы карарына
кушымта

**«Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районының Вознесенское торак массивындагы Чирмешән урамында Нокса елгасы аша күпер төзү» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты**

«Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районының Вознесенское торак массивындагы Чирмешән урамында Нокса елгасы аша күпер төзү» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты түбәндәгеләрдән тора:

I. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеш. Билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеген теркәп, кызыл линияләр, линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләре, урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы.

II. Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән линия объектын урнаштыру турында нигезләмә.

III. Территорияне ызанлау проекты. График өлеш. Территорияне ызанлау сызымы (1 нче этап).

IV. Территорияне ызанлау проекты. График өлеш. Территорияне ызанлау сызымы (2 нче этап).


V. Территорияне ызанлау проекты. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре (1 нче этап) чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре (2 нче этап) чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге һәм махсус бүленгән судан файдалану чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән текстлы өлеш.

Билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге, линия объектын план буенча урнаштыру зоналары

чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре (1 нче этап) чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре (2 нче этап) чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге һәм махсус бүленгән судан файдалану чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган документлар булып тора һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырылырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

# I. Территорияне планлаштыру проекты.

## График өлеш. Кызыл линияләр, линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләре һәм урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы



## II. Линия объектын урнаштыру турында нигезләмә

Территорияне планлаштыру проекты Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 29 августындагы 3679 номерлы «“Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районының Вознесенское торак массивындагы Чирмешән урамында Нокса елгасы аша күпер төзү” линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләү турында»гы карары нигезендә әзерләнде.

Административ яктан проектлана торган юл Казан шәһәренең Совет районында урнашкан. Ул Вознесенское торак массивының Чирмешән урамындагы юлның хәрәкәт итү өлешеннән һәм Нокса елгасы аша күпердән гыйбарәт.

Территориядә җир асты һәм җир өсте инженерлык челтәрләре урнашкан.

Территорияне планлаштыру проекты белән гомуми файдаланудагы территориянең чикләрен билгеләүче кызыл линияләр билгеләнә. Линия объектын план буенча урнаштыру чикләре Казан шәһәр округының генераль планы нигезендә проекттагы инженерлык челтәрләре буенча билгеләнә торган кызыл линияләр чикләрендә реконструкцияләнә торган автомобиль юлы урнашуны күздә тотып кабул ителгән. Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең зурлыгы, 42.13330.2016 номерлы «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү» кагыйдәләр җыелмасын исәпкә алып, максатка ярашлы булудан, объектның функциональ билгеләнешеннән чыгып кабул ителә.

«Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районының Вознесенское торак массивындагы Чирмешән урамында Нокса елгасы аша күпер төзү» линия объекты чикләрендә юл 42.13330.2016 номерлы «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү» кагыйдәләр җыелмасы һәм проектлаштыру биреме таләпләре нигезендә «Торак төзелеше зоналарындагы урамнар» категориясенә кертелгән.

Территорияне планлаштыру проекты мәйданы – 11 634 кв.м.

Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы мәйданы – 3 392 кв.м.

Линия объекты трассасының озынлыгы 195 метр тәшкил итә.

**Проектлана торган участокның техник характеристикалары һәм параметрлары**

| № т/б | Атамасы | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч |
|---|---|---|---|
| 1 | Төзелеш төре | | Төзелеш |
| 2 | Юл категориясе | | Торак йортлар зоналарындагы урамнар (42.13330.2016 номерлы кагыйдәләр җыелмасы нигезендә) |
| 3 | Трассаның озынлыгы | Км | 0,195 |
| 4 | Исәпләнгән тизлек | Км/сәг | 30 |
| 5 | Юл катламнары тибы һәм өслекнең төре | | Капиталь |
| 6 | Хәрәкәт полосалары саны | Данә | 2 |
| 7 | Хәрәкәт полосасы киңлеге | М | 3,00-4,00* |
| 8 | Машина юлының киңлеге | М | 6,00-8,00* |
| 9 | Пландагы кәкре сызыкның иң кечкенә радиусы | М | 40 (30**) |
| 10 | Күчәр буйлап иң зур авышлык | ‰ | 12 |
| 11 | Күчәр буйлап иң кечкенә авышлык | ‰ | 4 |
| 12 | Буй профильдә кәкре сызыкның иң кечкенә радиусы: | | |
| | - кабарынкы кәкре сызыкның | М | 12752 |
| | - батынкы кәкре сызыкның | М | 1932 |
| 13 | Исәпләнгән йөкләнешләр | кН | |
| | - юл киеменә | | 115 |
| 14 | Тротуар киңлеге | М | 1,50** |

Юлның техник характеристикалары һәм параметрлары 34.13330.2021 номерлы «2.05.02-85 төзелеш кагыйдәләре һәм нормалары* Автомобиль юллары» кагыйдәләр җыелмасы һәм 42.13330.2016 номерлы «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү» кагыйдәләр җыелмасы нигезендә кабул ителде.

Линия объектын план буенча урнаштыру зоналарының чикләре гамәлдәге җир кишәрлекләрен исәпкә алып билгеләнде.

Линия объектларын урнаштыру зоналары гамәлдәге нормативлар нигезендә билгеләнде. Әлеге объектларны башка ысул белән урнаштыру мөмкин түгел.

Линия объектларын урнаштыру зоналары чикләренә туры килә торган, урнаштыру әлеге кишәрлекләрне алардан рөхсәт ителгән файдалану төре буенча

куллану мөмкин булмауга китерәчәк яисә алардан файдалануда җитди кыенлыкларга китерәчәк җир кишәрлекләре һәм аларда урнашкан капиталь төзелеш объектлары муниципаль ихтыяҗлар өчен мәҗбүри алынырга тиеш.

Җирләрне бүлеп бирү күләмнәре проектлауның гамәлдәге нормаларын һәм кагыйдәләрен, төзелешне оештыру буенча карарларны исәпкә алып, җирләрне минималь мәҗбүри алу, технологик максатчанлык шартларыннан чыгып кабул ителә.

Объектларны төзү, эксплуатацияләү һәм төзекләндерү өчен махсус бүленгән җир полосасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 2 сентябрендәге 717 номерлы «Автомобиль юлларын һәм (яки) юл сервисы объектларын урнаштыру өчен җирләрне бүлеп бирү нормалары турында»гы карары нигезендә кабул ителде.

## Инженерлык инфраструктурасы объектларына характеристика

Проектта эксплуатацияләүче оешмаларның техник шартлары нигезендә юл янында яктырту һәм кар һәм яңгыр суларын агызу челтәрләрен төзү каралган.

Проект белән ябык типтагы яңгыр сулары канализациясе челтәрләре төзү, алга таба, локаль чистарту корылмаларында чистартылганнан соң, агынтыларны Нокса елгасына чыгару каралган.

## Линия объектын урнаштыруга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат

Планлаштыру проекты чикләрендәге территориядә Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрына һәм мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларның дәүләт исәбенә кертелгән мәдәни мирас объектлары юк.

## Әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын гамәлгә ашыру зарурлыгы турында мәгълүмат

«Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районының Вознесенское торак массивындагы Чирмешән урамында Нокса елгасы аша күпер төзү»

объектында, шул исәптән алга таба проект һәм төзелеш-монтаж эшләре кысаларында, табигатьне саклау чараларына 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында»гы федераль законның, Россия Федерациясе Җир кодексының, ГОСТ 17.4.3.02-85, ГОСТ Р 59070-2020, ГОСТ Р 59060-2020, ГОСТ 17.5.1.03-86, ГОСТ 17.5.1.06-84, ГОСТ Р 59057-2020, ГОСТ 17.5.3.05-84, ГОСТ 17.5.3.06-85 һәм башкаларның гамәлдәге норматив таләпләре нигезендә оператив һәм кисәтү чаралары кертелергә тиеш.

**Территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнар оборонасын тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру зарурлыгы турында мәгълүмат**

Автомобиль юлы җитештерү циклы объекты булып тормый һәм үз составында куркыныч җитештерүләр һәм аларның участоклары юк.  Шулай ук объектта куркыныч матдәләр юк. Димәк, авария нәтиҗәсендә куркыныч матдәләр чыгуны (чыгаруны) бетерү турында карарлар проектлаштыруга бирем белән билгеләнми һәм проектта күздә тотылмый.

Төзелеш корылмалары җимерелүгә бәйле аварияләр үсешен кисәтү эксплуатацияләүче оешма көчләре белән даими күзәтү һәм мониторинглау хисабына һәм, авария хәле барлыкка килгән очракта, ЮХИДИ  органнары белән берлектә эксплуатацияләүче оешма карары буенча автомобиль юлы буенча хәрәкәтне туктатып (чикләп), мондый аварияләрнең башлангыч билгеләрен ачыклау белән ирешелә.

Проектлана торган объектлар урнашу районында куркыныч табигый процесслар (ишелүләр, сил ташкыннары, кар ташкыннары һ.б.) булмый.

Проектлана торган корылмаларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен, шул исәптән проектлауның алдагы этапларында да, 2009 елның 30 декабрендәге 384-ФЗ номерлы «Биналар һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент» федераль законында билгеләнгән чараларны күздә тоту зарур.


Проектлана торган линия объекты территориясенә иң якын урнашкан янгыннан саклау бүлекчәсе – Казан шәһәре, Кол Гали урамы, 4 йортта урнашкан 7 номерлы янгын сүндерү бүлеге.

## Гражданнар оборонасы буенча чаралар


Линия объектының карап тикшерелә торган территориясе мөмкин булган җимерелүләр, химик һәм радиоактив зарарлану, һәлакәтле су басу зоналарына эләкми. Гражданнар оборонасы буенча махсус чаралар әзерләү һәм үткәрү таләп ителми.

**III. Территорияне ызанлау проекты. График өлеш.**

**Территорияне ызанлау сызымы (1 нче этап).**



**IV. Территорияне ызанлау проекты. График өлеш.**
**Территорияне ызанлау сызымы (2 нче этап).**



## V. Территорияне ызанлау проекты. Текстлы өлеш

Ызанлау проекты җир кишәрлекләренең чикләре планын үз эченә ала һәм фактта җирдән файдалануны, әлеге территориядә билгеләнгән шәһәр төзелеше нормативларын исәпкә ала. Җир кишәрлекләре ясауның хокукый яктан нигезләнгән булуы гамәлдәге законнар һәм муниципаль дәрәҗәдәге норматив актлар белән билгеләнгән.

«Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районының Вознесенское торак массивындагы Чирмешән урамында Нокса елгасы аша күпер төзү» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты Казан шәһәренең Совет районы территориясендә эшләнде.

Территорияне ызанлау проекты линия объектын план буенча урнаштыру чикләрендә территорияне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләрен формалаштыру, гамәлдәге капиталь төзелеш объектларын исәпкә алып, кызыл линияләр билгеләү максатыннан әзерләнде.

2020 елның 31 июлендәге 254-ФЗ номерлы «Инфраструктураны модернизацияләү һәм киңәйтү буенча өстенлекле проектларны гамәлгә ашыру максатыннан аерым мөнәсәбәтләрне җайга салу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль законның 3 статьясындагы 2 пункты нигезендә инфраструктура объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре мондый инфраструктура объектлары территориясен планлаштыру буенча расланган документлар белән билгеләнә.

Линия объектын план буенча урнаштыру чикләрендә гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләрен төзү максатыннан 2 этапта кадастр эшләре башкару таләп ителә.

Һәр этапта ясала торган җир кишәрлекләре турындагы белешмәләр, шул исәптән беренчел һәм ясала торган җир кишәрлекләре мәйданы, рөхсәт ителгән файдалану төре турындагы белешмәләр, мөмкин булган ясау ысуллары һәм дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен мәҗбүри алу турында белешмәләр таблицада бирелгән.

Таблица

**Ясала торган җир кишәрлекләре исемлеге**

| Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры | Беренчел җир кишәрлегенең милек формасы | Беренчел җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төре | Ясала торган җир кишәрлегенең билгеләнеше | Мәйданы, кв.м | Билгеләнә торган рөхсәт ителгән файдалану төре | Ясалу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 нче этап | | | | | | |
| - | - | - | ЗУ1<br><br>(1 контур)<br>(2 контур)<br>(3 контур) | 1398<br><br>(754)<br>(397)<br>(247) | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән җир кишәрлеге ясау |
| - | - | - | ЗУ2<br><br>(1 контур)<br>(2 контур)<br>(3 контур) | 612<br><br>(353)<br>(47)<br>(212) | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән җир кишәрлеге ясау |
| 16:50:270255:65 | Дәүләт милке | Нокса елгасы | 16:50:270255:65:ЗУ1<br><br>(1 контур)<br>(2 контур) | 38<br><br>(36)<br>(2) | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Беренчел җир кишәрлеген саклаган хәлдә үзгәртелгән чикләрдә бүлү |
| 16:50:270255:20 | Хосусый милек | Төзелеш тәмамланмаган объект һәм янәшәдәге территория өчен | 16:50:270522:20:ЗУ1 | 1100 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Беренчел җир кишәрлеген саклаган хәлдә үзгәртелг |

| Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры | Беренчел җир кишәрлегенең милек формасы | Беренчел җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төре | Ясала торган җир кишәрлегенең билгеләнеше | Мәйданы, кв.м | Билгеләнә торган рөхсәт ителгән файдалану төре | Ясалу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | ән чикләрдә бүлү |
| 2 нче этап | | | | | | |
| ЗУ1<br>ЗУ2<br>16:50:270255:65:ЗУ1<br>16:50:270255:20:ЗУ1<br>16:50:270255:491<br>16:50:270255:20 | | | ЗУ4 | 2817 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне яңадан бүлү |
| | | | ЗУ5 | 593 | Коммуналь хезмәтләр күрсәтү (3.1.1) | Муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне яңадан бүлү |

* Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясындагы 3 пункт нигезендә билгеләнгәнчә, җир кишәрлекләре ясау өчен нигез булып торган җир кишәрлекләренең

максатчан билгеләнеше һәм алардан рөхсәт ителгән файдалану төре ясала торган җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнеше һәм алардан рөхсәт ителгән файдалану төре дип таныла. Кадастр эшләрен башкарганнан соң, ЗУ5 җир кишәрлегенә «Коммуналь хезмәтләр күрсәтү (3.1.1)» рөхсәт ителгән файдалану төрен билгеләргә тәкъдим ителә.

Россия Федерациясе Җир кодексының 11.4 статьясындагы 6 пунктының 3 пунктчасы нигезендә линия объектын урнаштырырга дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлеге өлешен мәҗбүри алу максатыннан үзгәртелгән чикләрдә беренчел җир кишәрлеген саклап бүлү башкарыла.

Кадастр эшләренең 2 нче этабын башкару алдыннан 2 нче этапта ясала торган җир кишәрлекләре өчен беренчел булып торган җир кишәрлекләренә Казан шәһәренең муниципаль милек хокукын теркәү зарур.

2 нче этапта ясала торган җир кишәрлекләре  өчен беренчел булып торган җир кишәрлекләре чиктәш булып санала.

Су объектының яр буе линиясе чикләрендә ызанлау проекты белән ЗУ3 махсус билгеләнгән судан файдалану каралган. 2006 елның 3 июнендәге 74-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең Су кодексы» нигезендә су объектлары файдалануга судан файдалану шартнамәләре буенча бирелә. Проектлауның алдагы этапларында әлеге шартнамәне төзү күздә тотыла.

**Гомуми файдаланудагы территорияләргә яисә гомуми файдаланудагы милеккә кертеләчәк ясала торган җир кишәрлекләре исемлеге һәм аларның мәйданы турында белешмәләр (1 нче этап)**

| Шартлы билге | Җир кишәрлеге мәйданы, кв.м | Ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре | Мәҗбүри алу |
|---|---|---|---|
| ЗУ1 | 1398 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | – |
| ЗУ2 | 611 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | – |
| 16:50:270255:65:ЗУ1 | 38 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | – |
| 16:50:270255:20:ЗУ1 | 1100 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | – |

| **Шартлы билге** | **Җир кишәрлеге мәйданы, кв.м** | **Ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Мәҗбүри алу/ резервлау** |
|---|---|---|---|
| 16:50:270255:20 | 2151 | Төзелеш эшләре тәмамланмаган объект һәм аның янындагы территория | Тулысынча мәҗбүри алу |
| 16:50:270255:65 | 38 | Нокса елгасы | Өлешчә резервлау |
| 16:50:270255:491 | 20 | Территорияне төзекләндерү | Тулысынча резервлау |

16:50:270255:20 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан 16:50:270255:100 кадастр номерлы капиталь төзелеш объекты шулай ук мәҗбүри алынырга тиеш.

## Гомуми файдаланудагы территорияләргә яисә гомуми файдаланудагы милеккә кертеләчәк ясала торган җир кишәрлекләре исемлеге һәм аларның мәйданы турында белешмәләр (2 нче этап)

| **Шартлы билге** | **Җир кишәрлеге мәйданы, кв.м** | **Рөхсәт ителгән файдалану төре** |
|---|---|---|
| ЗУ4 | 2817 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) |
| ЗУ5 | 593 | Коммуналь хезмәтләр күрсәтү (3.1.1) |